**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең  Каенлык авылында гражданнар җыены карары**

11 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең  Каенлык авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Зур Фролово авыл җирлегенең  Каенлык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия  балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә

- Каенлык авылында зиратны төзекләндерүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Зур Фролово авыл җирлегенең  Каенлык авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Зур Фролово авыл җирлеге башлыгы _________  О.Г. Масленцева

Халык җыены секретаре _________  В.А. Антипова